КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2020 ел, 7 сентябрь | г.Казань | № 800

2020 елга Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләре ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

2021 елга Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләре ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны;

2021 елга Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләре ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүне тәэмин итүгә норматив чыгымнарны муниципаль һәм дәүләт оешмалары, шулай ук муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан коммерциягә караган һәм коммерциягә карамаган оешмалар (муниципаль һәм дәүләт оешмаларыннан тыш) хезмәткәрләре балалары арасыннан бер балага 51,9 сум күләмендә расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«2020 елга Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләре ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2019 ел, 6 сентябрь, 791 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2020 елга Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләре ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарны раслау турында» 2019 ел, 6 сентябрь, 791 нче карары белән расланган 2020 елга Татарстан Республикасы балалары һәм яшьләре ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә норматив чыгымнарга үзгәрешләр кертү хакында» 2020 ел, 4 август, 649 нчы.

3. Бу карар 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 7 сентябрь, 800 нче
карары белән расланды

2021 елга Татарстан Республикасы балалары һәм
яшьләре ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә
норматив чыгымнар

| Т/с | Балалар һәм яшьләр ялын оештыру формасы | Норматив чыгымнар, бер көнгә бер кешегә койка-урынга сум |
|---|---|---|
| 1. | Шәһәр яны ял лагерындагы смена | 855,96 |
| 2. | Шәһәр яны ял лагерындагы юнәлешле смена һәм төрле тематик юнәлештәге смена | 845,47 |
| 3. | Палатка тибындагы лагерьдагы смена | 1035,74 |
| 4. | Белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган көндезге ял лагерындагы, хезмәт һәм ял лагерендагы смена | 180,96 |
| 5. | Югары белем бирүче мәгариф оешмалары студентлары өчен физкультура-сәламәтләндерү чаралары | 163,54 |
| 6. | Шифаханә-курорт оешмасындагы смена | 1305,55 |
| 7. | Кара диңгез яры буендагы шәһәр яны ял лагерындагы юнәлешле смена һәм төрле тематик юнәлештәге смена | 1690,41 |

_______________